ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ / КАРАР

30.01.2019 с. Верхний Услон 56

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районында җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирләү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында күмү һәм җирләү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы карары, «2019 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү күләмен раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2019 елның 24 гыйнварындагы 32 номерлы карары белән туры китереп, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты, КАРАР БИРӘ:

1. 2019 елның 1 февраленнән Югары Ослан муниципаль районында җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 1 нче кушымта һәм 2 нче кушымта нигезендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.
2. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районында җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәяләрен раслау турында» 2018 ел, 31 гыйнвар, 109 нчы карары үз көчен югалткан дип санарга.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль-икътисадый үсеш буенча урынбасары йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **Л.С. Хакимзянов**

Югары Ослан муниципаль районы
Башкарма комитетының
30.01.2019 № 56 карарына
1 кушымта

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районында 01.02.2019 елдан җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле
БӘЯЛӘРЕ

| **Хезмәт күрсәтү исеме** | **Хезмәт күрсәтү бәясе *(сумнарда)*** |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 87,88 |
| 2. Күмү өчен кирәкле табутны һәм башка әйберләрне бирү һәм китерү. | 3240,53 |
| 3. Зиратка үлгән кешенең мәетен (җәсәден) алып бару | 923,12 |
| 4. Күмү (кабер казу һәм күмү ) | 1694,94 |
| **Барлыгы** | **5946,47** |

Югары Ослан муниципаль районы
Башкарма комитетының
30.01.2019 № 56 карарына
2кушымта

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районында 01.02.2019 елдан җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле
БӘЯЛӘРЕ

| **Хезмәт күрсәтү исеме** | **Хезмәт күрсәтү бәясе *(сумнарда)*** |
|---|---|
| 1. . Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 87,88 |
| 2. Җәсәдләү | 572,51 |
| 3. Күмү өчен кирәкле табутны һәм башка әйберләрне бирү һәм китерү. | 2668,02 |
| 4. Зиратка үлгән кешенең мәетен (җәсәдләрен) алып бару | 923,12 |
| 5. Күмү (кабер казу һәм күмү ) | 1694,94 |
| **Барлыгы** | **5946,47** |